**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Түбән Чәке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Югары Чәке авылында гражданнар җыены КАРАРЫ**

**21 нче ноябрь 2023 ел Югары Чәке авылы №1**

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы "Түбән Чәке авыл җирлеге " муниципаль берәмлегендә Югары Чәке авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге Советы 10.10.2019 ел, № 52/1 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда, гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә, 2023 елның 21 ноябрендә төзелгән Хисап комиссиясенең, 2023 елның 21 ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә, тавыш бирү тәмамланган вакытта, җыенда катнашучы 51 кеше кертелгән, гражданнар җыенында катнашучыларның тавыш бирүдә катнашкан саны-**39**, бу исемлеккә кертелгән гражданнарның **76,47** % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан **39** кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде, бу гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучыларның **100%** ын тәшкил итә; «Каршы» позициясе өчен, җыенда катнашучы **0** кеше тавыш бирде, бу **0%** тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә карар иттеләр:

1. 2023 елның 21 ноябрендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Түбән Чәке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Югары Чәке авылында 2023 елның 21 ноябрендә уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләрен-дөрес дип танырга.

2."Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Түбән Чәке авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту.

3. 2024 елда Чүпрәле муниципаль районының Түбән Чәке  авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту.

4. Салым түләүдән азат итү:

1) 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнар;

2) инвалид балаларның ата-аналары (уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр), тулы Дәүләт тәэмин итүендә булган балалардан тыш;

3) махсус хәрби операциядә катнашучылар;

4) махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзалары (тормыш иптәше (хатыны), балигъ булган балалар, ата-аналар һәм башка эшкә сәләтсез тәрбияләнүчеләр), шул исәптән махсус хәрби операция барышында хәбәрсез югалган һәлак булганнар;

5) Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында»2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указына ярашлы рәвештә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар;

6) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаилә әгъзалары (тормыш иптәше (хатыны), балигъ булган балалары, ата-аналары һәм башка эшкә сәләтсез тәрбияләнүчеләр)

5. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә: Түбән Чәке авылы, Совет урамы, 11 нче йорт, МФЦ бинасы янында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
Түбән Чәке  авыл җирлеге башлыгы,
халык җыенында рәислек итүче: А.В.Солдатов